КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 26 декабрь г.Казань № 1207

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие турында» 2019 ел, 7 сентябрь, 803 нче карары белән расланган 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына айлык пособие бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гаилә әгъзаларына (ата-аналарының берсе генә инвалид булган һәм (яки) балаларының берсе генә инвалид булган гаиләләрдән тыш) айлык пособие Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү турында» 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәмен, шул исәптән социаль контракт нигезендә, күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмә белән күздә тотылган тәртиптә бирелә.»;

2 нче пунктта «18 яшькә кадәрге кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган» сүзләреннән соң «, ата-аналарының берсе генә инвалид һәм (яки) балаларының берсе генә инвалид булган» сүзләрен өстәргә;

4 нче пунктта «18 яшькә кадәрге кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган» сүзләрен «алучы» сүзенә алыштырырга;

11 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Алучының һәм аның гаилә әгъзаларының ризалыгы булганда һәм аның һәм аның гаилә әгъзаларының башка төр керемнәре булмаганда, айлык пособие билгеләү бу Тәртипнең 6 нчы пунктындагы алтынчы абзацында күрсәтелгән, Россия Федерациясе Пенсия фондында булган, айлык пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәр килгән 12 айның соңгы алты аена бирелгән мәгълүматлар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

2. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин